Республика Татарстан

Татарстан Республикасы

**ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**“**10 **”** 06 2020 **г.** №34

Татарстан Республикасы Ютазы муниипаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, Россия Федерациясе гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ Закон, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге УП-598 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмә”не расларга.
2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләренә, аларның оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, гамәлдәге законнар нигезендә «Оешмада гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмә»не эшләргә һәм расларга кушарга.
3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгының «Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында"гы 2016 елның 1 февралендәге №9 карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы урынбасары З. М. Әгълиева

Р. М. Якупов
2-74-14

Кушымта
Ютазы муниципаль
районы башлыгы
урынбасары карарына
«____»_________20___ ел № _____

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла - казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы нигезендә эшләнгән һәм гражданнар оборонасын алып бару, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында (алга таба - ТР Ютазы муниципаль районы) гражданнар оборонасы буенча төп чараларны билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасы буенча чаралар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасын алып баруга эзерлек һәм аны алып бару кысаларында оештырыла.

3. Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек халыкны, хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлардан, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауга әзерлек чараларын алдан ук үтәүдән гыйбарәт һәм Ютазы муниципаль районының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча төп чараларны (алга таба - ТР Ютазы муниципаль районының төп чаралар планы) күздә тоткан еллык план нигезендә тормышка ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының бер елга төп чаралар планы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты) тарафыннан эшләнә, һәм Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының территориаль органы - Татарстан Республикасы буенча гражданнар оборонасы бурычларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча махсус вәкаләтле орган - Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе белән килештерелә.

Гражданнар оборонасының төп чараларын әзерләү һәм алып баруны планлаштыру ТР Ютазы муниципаль районы территориясендә хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук мөмкин булган террорлык актлары һәм гадәттән тыш хәлләр

нәтиҗәсендә килеп чыгарга мөмкин булган хәлне һәрьяклап бәяләүне исәпкә алып башкарыла.

5. Муниципаль дәрәҗәдә гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек муниципаль берәмлектә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмә белән билгеләнә һәм ТР Ютазы муниципаль районы территориясендә халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда яклау чараларын планлаштырудан гыйбарәт.

Гражданнар оборонасын муниципаль дәрәҗәдә алып бару Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы нигезендә гамәлгә ашырыла һәм Ютазы муниципаль районы территориясендә халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә килеп туган куркынычлардан саклау буенча чараларны үтәүдән гыйбарәт.

6. Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы гражданнар оборонасын хәрби чорда техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чараларның күләмен, оештырылуын, тәртибен, ысулларын һәм вакытларын билгели.

Тыныч вакытта гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чараларны үтәү табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чаралар планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы идарәсе органнары, көчләре һәм чаралары белән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итүче оешмалар исемлеген билгели.

7. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатларында, гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләр нигезендә көчләрне, чараларны, гражданнар оборонасы объектларын, матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыра, гражданнар оборонасы чараларын планлаштыра һәм тормышка ашыра.

8. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча коткару хезмәтләре (медицина тәэминаты һәм санитар-эпидемиология күзәтчелеге, энергетика, инженер, коммуналь-техник, янгынга каршы, җәмәгать тәртибен саклау, хайваннарны һәм үсемлекләрне саклау, элемтә һәм хәбәр итү, ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү, юл, сәүдә һәм туклану) оештырыла ала, аларның оештыру һәм эшчәнлек тәртибе аларны булдырган органнар һәм оешмалар тарафыннан коткару хезмәтләре турында тиешле нигезләмәләрдә билгеләнә.

Коткару хезмәте составына Гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү, авария-коткару формированиеләренең гамәлләрен төрле яклап тәэмин итү һәм сугыш конфликтларында яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә башка кичектергесез эшләрне башкару, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерүдә гражданнар оборонасы идарә органнары, көчләре һәм чаралары керә.

Коткару хезмәтләренең төре һәм саны гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планнары нигезендә башкарыла торган эшләрнең күләмен һәм характерын исәпләү нигезендә билгеләнә.

ТР Ютазы муниципаль районының коткару хезмәте турындагы нигезләмә коткару хезмәте җитәкчесе тарафыннан эшләнә, Татарстан Республикасының тиешле коткару хезмәте җитәкчесе белән килештерелә һәм ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы көчләренең һәм гражданнар оборонасы чараларының әзерлеген булдыру һәм тәэмин итү белән методик җитәкчелек итү, шулай ук бу өлкәдә контроль Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла - казалар нәтиҗәләрен бетерү эшләре министрлыгы (алга таба-Россия ГТХМ) һәм Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты эвакуация чараларын планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү өчен тыныч вакытта алдан эвакуация комиссиясе төзелә. Эвакуация комиссиясен ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары җитәкли. Эвакуация комиссиясе эшчәнлеге ТР Ютазы муниципаль районының гражданнар оборонасы җитәкчесе тарафыннан расланган эвакуация комиссиясе турында Нигезләмә белән регламентлана.

10. Гражданнар оборонасы көчләре тыныч вакытта табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чараларда катнашу өчен җәлепителергә мөмкин.

Тыныч вакытта гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турындагы карарны ТР Ютазы муниципаль районы гражданнар оборонасы җитәкчесе үзе төзегән гражданнар оборонасы көчләренә карата кабул итә.

11. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы җитәкчесе булып Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тора.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау чараларын оештыру һәм үткәрү өчен шәхси җаваплылык тота.

12. ТР Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы орган булып, гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә төзелә торган структур бүлекчә тора.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә бурычларны хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчәне туплый, функциональ вазыйфаларны һәм штат расписаниесен эшли һәм раслый.

Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә бурычларны хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчә җитәкчесе турыдан-туры ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә буйсына.

13. Гражданнар оборонасы буенча чараларны оешкан төстә һәм планлы рәвештә гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шул исәптән тыныч һәм сугыш вакытында фаразланган һәм

барлыкка килгән куркынычлар турында халыкка үз вакытында хәбәр итү максатыннан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм аның белән уртаклашу оештырыла.

ТР Ютазы муниципаль районы территориясендә мәгълүмат җыю һәм алмашу «ТР Ютазы муниципаль районы гражданнарны яклау идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан башкарыла.

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гражданнарны яклау идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тапшыра.

14. Гражданнар оборонасы буенча чаралар муниципаль дәрәҗәдә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы җитәкчесенең күрсәтмә документлары, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

15. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатларында, түбәндәге төп чараларны планлаштыра һәм гамәлгә ашыра:

15.1. Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны әзерләү буенча:

ТР Ютазы муниципаль районы үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган үрнәк программалар нигезендә эшләүче халыкны, вазыйфаи затларны һәм гражданнар оборонасы хезмәткәрләрен, ТР Ютазы муниципаль районы формированиеләренең һәм хезмәтләренең шәхси составын әзерләү буенча эшләү;

ТР Ютазы муниципаль районы халкын хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлардан саклау, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп туган очраклардан саклану ысулларына әзерләү һәм оештыру;

ТР Ютазы муниципаль районы формированиеләренең һәм хезмәтләренең шәхси составын әзерләү;

Гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм тренировкалар үткәрү;

ТР Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан хезмәткәрләрнең, шәхси составның һәм хезмәтләрнең әзерлеген оештыру-методик җитәкчелек итү һәм контрольдә тоту;

гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктларын булдыру, җиһазлау һәм аларның эшчәнлеген оештыру, шулай ук тиешле лицензиясе булган өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларында ТР Ютазы муниципаль районы гражданнар оборонасы һәм вазифаи затларның квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

гражданнар оборонасы өлкәсендә белемнәрне пропагандалау.

15.2. Халыкка хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар аркасында килеп чыккан куркынычлар турында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта хәбәр итү:

үзәкләштерелгән халыкка хәбәр итү системасын даими әзерлектә тоту, аны реконструкцияләү һәм модернизацияләү;

кешеләр күпләп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру;

мәгълүмат тапшыруның Россия Федерациясе бердәм электр элемтәсе челтәре, радио-, үткәргеч һәм телевизион тапшырулар чаралары һәм башка техник чараларны комплексы файдалану;

гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм аның белән алмашу.

15.3. Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү буенча:

халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркыныч зоналардан имин районнарга эвакуацияләү буенча чараларны планлаштыру, әзерләү һәм үткәрүне оештыру, шулай ук үз эшчәнлеген сугыш чорында дәвам итүче оешма хезмәткәрләрен һәм куркыныч янаган зоналарда гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче оешма хезмәткәрләрен урнаштыру;

халыкны, эвакуацияләнергә тиешле матди һәм мәдәни кыйммәтләрне урнаштыру өчен куркынычсыз районнар әзерләү;

эвакуация органнарын булдыру һәм аларның эшчәнлеген оештыру, шулай ук аларның шәхси составын әзерләү.

15.4. Халыкка шәхси һәм коллектив саклану чаралары бирү буенча:

гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм аларның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү системаларын һәм техник хезмәт күрсәтүне билгеләнеше буенча даими әзерлек хәлендә тоту, саклау;

тыныч вакытта һәм гражданнар оборонасын тыныч вакыттан хәрби вакытка күчергәндә, халыкны урнаштыру өчен тирәнәйтелгән урыннарны һәм җир асты киңлекләренең башка корылмаларын җайлаштыру;

сугыш вакытында гражданнар оборонасының җитмәгән саклагыч корылмаларын планлаштыру һәм төзүне оештыру;

гражданнар оборонасының саклау корылмаларында һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларында халыкның яшеренүен тәэмин итү;

халыкны шәхси саклау чараларын туплау, саклау, яңарту һәм билгеләнеше буенча куллану;

билгеләнгән срокта халыкка шәхси саклану чараларын һәм коллектив саклану чараларын бирүне тәэмин итү.

15.5. Яктылык һәм башка төр маскировка буенча:

маскировкаланырга тиеш булган объектлар исемлеген билгеләү;

билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы төркемнәренә кертелгән территорияләрне комплексы маскировкалау планнарын эшләү;

яктырткыч һәм башка төр маскировка чаралары үткәрү өчен кирәкле матди-техник чаралар запасларын билгеләнешләре буенча куллану буенча даими әзерлек хәлендә тоту;

15.6. Хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халык өчен куркыныч туган очракта, һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләрне үткәрү буенча:

гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасын булдыру, җиһазлау һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;

авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне һәрьяклап тәэмин итү өчен матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын куллану буенча даими әзерлек хәлендә тоту һәм аны булдыру.

15.7. Хәрби конфликтларда яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә зыян күргән халыкны, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә беренче чиратта тормыш белән тәэмин итү буенча:

халыкның беренчел яшәешен тәэмин итүнең төп төрләрен планлаштыру һәм оештыру;

матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм билгеләнеше буенча кулланууны даими әзерлек хәлендә тоту;

халыкны азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән нормалаштырылган тәэмин итү;

халыкка коммуналь-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү;

зыян күргән халык арасында санитар-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

дәвалау-эвакуация чаралары үткәрү;

куркынычсыз районда кирәкле дәвалау базасын җәелдерү, аны энергия һәм су белән тәэмин итүне оештыру;

халыкка беренче ярдәм күрсәтү;

тораксыз калган халык санын билгеләү;

сакланган торакны инвентаризацияләү һәм зыян күргән торак фондының торышын бәяләү, зыян күргән халыкны урнаштыру өчен аны куллану мөмкинлеген билгеләү;

зыян күргән халыкны ял йортларында, пансионатларда һәм башка сәламәтләндерү учреждениеләрендә, вакытлыча торакларда (җыелма йортларда, палаткаларда, землянкаларда) урнаштыру, шулай ук аны сакланып калган торак фонд мәйданына күчерү;

халыкка мәгълүмати-психологик ярдәм күрсәтү.

15.8. Хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән янгыннарга каршы көрәш буенча:

муниципаль янгын сагын булдыру һәм эшчәнлеген оештыру, аны гражданнар оборонасы һәм янгын саклауның башка төрләре белән хезмәттәшлек итү өлкәсендә әзерләүне оештыру;

авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару районнарында һәм билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категориясенә кертелгән оешмаларда янгыннарны сүндерүне оештыру;

янгыннарны сүндерү өчен химик реагентлар запасларын алдан ук булдыру.

15.9. Радиоактив, химик, биологик һәм башка зарарланган (пычранган) районнарны ачыклау һәм билгеләү буенча:

гражданнар оборонасын күзәтү һәм лаборатор контроль челтәрен булдыру һәм халыкны яклау - гамәлдәге махсуслаштырылган учреждениеләр, башкарма хакимиятнең федераль органнары бүлекчәләре һәм хезмәтләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә радиацион, химик, биологик хәлләрне күзәтү һәм тикшереп тору функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмалар булдыру һәм аларның әзерлеген тәэмин итү;

радиоактив пычрануга дучар булган территорияләрдә радиацион саклау режимнарын кертү.

15.10. Халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү буенча:

алдан дезактивлаучы, газсызландыручы һәм дезинфекцияләүче матдәләр һәм эремәләр запасларын булдыру;

халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү өчен көчләр булдыру һәм җиһазлау, аларны гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү чараларын үткәрүне оештыру.

15.11. Хәрби конфликтларда яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык акцияләре нәтиҗәсендә зыян күргән районнарда тәртипне тергезү һәм саклау буенча:

җәмәгать тәртибен саклау көчләрен булдыру һәм җиһазлау, аларны гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

халыкны эвакуацияләү маршрутларында җәмәгать тәртибен торгызу һәм саклау, гражданнар оборонасы көчләре хәрәкәте һәм халыкны эвакуацияләү маршрутларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;

авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен гражданнар оборонасы көчләренең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итү;

зарарлану учакларында пропуск режимын гамәлгә ашыру һәм җәмәгать тәртибен саклау;

Эчке эшләр органнары тарафыннан юридик һәм физик затларның шартнамәләр буенча мәҗбүри сакланырга тиешле объектларны саклауларын көчәйтү, караучысыз калган мөлкәтне саклау буенча чаралар күрү.

15.12. Хәрби вакытта кирәкле коммуналь хезмәтләрнең тиз арада эшләвен торгызу мәсьәләләре буенча:

коммуналь хезмәтләрнең хәрби вакыт шартларында эшләүгә әзерлеген тәэмин итү, аларның эшен планлаштыру;

зарарланган газ, энергия, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу һәм канализация системаларын ремонтлау өчен җиһазлар һәм запас частьләр запасларын булдыру;

суны чистарту, тозсызландыру һәм транспортлау өчен мобиль чаралар резервын булдыру һәм әзерләү;

суүткәргеч станцияләрдә реагентларның, реактивларның, консервантларның һәм дезинфекцияләү чараларының кирәкле запасларын булдыру;

резервуарлар һәм сыемнар запасларын, җыела-сүтелә торган торба үткәргечләрен, мобиль резерв һәм автоном энергия чыганакларын, халыкны коммуналь тәэмин итүне оештыру өчен җиһазлар һәм техник чаралар булдыру.

15.13. Сугыш вакытында мәетләрне ашыгыч рәвештә күмү буенча:

алдан, тыныч вакытта, күмелү урыннарын билгеләү;

мәетләрне күмү чараларын тәэмин итү өчен, шул исәптән махсуслаштырылган ритуаль оешмалар базасында көчләрне һәм гражданнар оборонасы чараларын булдыру, әзерләү һәм әзерлекләрен тәэмин итү;

һәлак булган кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) җирләү (күмү) урыннарын җиһазлау;

мәетләрне эзләү, аларның табылу урыннарын теркәү, аларны алу һәм беренчел эшкәртү, үлүчеләрне тану һәм документлаштыру, ташу (перевозка) һәм күмү эшләрен оештыру;

санитар-эпидемиологик күзәтчелекне оештыру.

15.14. Хәрби конфликтларда яисә әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның исән калу өчен кирәкле оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү буенча:

тыныч һәм хәрби вакытта икътисад эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча комиссия булдыру һәм аның эшен оештыру;

икътисад һәм инфраструктура объектларын, шулай ук җитештерү чараларын төзелеш нормалары һәм гражданнар оборонасының инженер-техник чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләре таләпләренә туры китереп рациональ урнаштыру;

куркыныч чорда комплекслы маскировкалау буенча чаралар планлаштыру һәм уздыру;

энергия һәм су белән тәэмин итү системаларының һәм чыганакларының ышанычлылыгын күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм үткәрү;

тыныч вакытта һәм сугыш вакытында гражданнар оборонасының инженер-техник чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, шул исәптән төзелеш проектларында;

сугыш чорында икътисад объектларында эшне дәвам итә торган авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне планлаштыру, әзерләү һәм уздыру;

җитештерү процессын торгызу өчен кирәкле матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын алдан булдыру;

документациянең иминият фондын булдыру;

заманча зарарлау чаралары тәэсирендә җитештерү фондларын саклауның нәтиҗәлелеген арттыру.

15.15. Гражданнар оборонасы көчләренең һәм чараларының даими әзерлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча:

гражданнар оборонасы көчләрен заманча техника һәм җайланмалар белән тәэмин итү;

гражданнар оборонасы көчләрен эш итүгә әзерләү, гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм тренировкалар үткәрү;

гражданнар оборонасы көчләренең эшен планлаштыру;

гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү һәм үзара хезмәттәшлек тәртибен билгеләү, шулай ук аларның гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү.

16. ТР Ютазы муниципаль районының гражданнар оборонасы чараларын финанслау гамәлдәге законнар нигезендә тормышка ашырыла.